**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе белән бүләкләү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе турында» 2011 елның 27 декабрендәге ПУ-873 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 12 августындагы ПУ-684 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) преамбулада «гражданлыксыз затларны,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен» сүзләрен өстәргә;

б) Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе турында нигезләмәдә:

2 пунктта «(алга таба – гражданнар)» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре» сүзләрен өстәргә;

4 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары җитәкчеләрен һәм коллективларын (җирле үзидарә коллегиаль органнары вәкилләрен);»;

10 пунктта «гражданны» сүзеннән соң «, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге» сүзләрен өстәргә;

11 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле яңа икенче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеген бүләкләү турындагы үтенечнамәгә әлеге Нигезләмәнең $2^1$ нче кушымтасында бирелгән формада тутырылган гариза кәгазе һәм әлеге Нигезләмәнең $2^2$ нче кушымтасында бирелгән исемлек буенча документлар теркәп бирелә.»;

икенче абзацны өченче абзац дип санарга;

өченче абзацны дүртенче абзац дип санарга һәм «гражданның» сүзеннән соң «, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең» сүзләрен өстәргә;

12 пунктның беренче абзацына «(татар телендә – Россия Федерациясе гражданы паспортында гражданның шәхесе турында татар телендәге мәгълүматлы өстәмә бит булганда),» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасының Рәхмәт сүзе белән бүләкләүгә тәкъдим ителә торган муниципаль берәмлегенең атамасы аның уставы нигезендә рус һәм татар телләрендә языла,» дигән сүзләрне өстәргә;

15 пунктның «б» пунктчасын «тиешле категорияләрен,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен,» сүзләрен өстәргә;

17 пунктта «гражданнарның» сүзеннән соң «, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең» сүзләрен өстәргә;

18 пунктта «(гражданны Рәхмәт сүзе белән бүләкләүгә тәкъдим иткәндә)» сүзләреннән соң «, $2^2$ нче кушымтада (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеген Рәхмәт сүзе белән бүләкләүгә тәкъдим иткәндә)» сүзләрен өстәргә;

19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Тәкъдим билгеләнгән тәртиптә башта Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе тарафыннан карала. Тәкъдимне карау йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе:

Татарстан Республикасы Президентына хуплау турында тәкъдим кертә;

әлеге Нигезләмәнең 20 пунктында каралган очракларда тәкъдимне кире кага;

Рәхмәт сүзе белән бүләкләүгә тәкъдим ителгән затны, «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законында каралган җитәрлек нигезләр барлыгы ачыкланганда, Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турында Татарстан Республикасы Президентына тәкъдим кертә.»;

20 пунктка түбәндәге эчтәлекле «$г^1$» пунктчасын өстәргә:

«$г^1$) Рәхмәт сүзе белән бүләкләүгә тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең үзгәртеп корылуы яисә бетерелүе;»;

24 пунктта «гражданнар» сүзеннән соң «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре,» сүзләрен өстәргә;

1 нче кушымта нигезендә $2^1$ нче кушымта өстәргә;

2 нче кушымта нигезендә $2^2$ нче кушымта өстәргә;

в) Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе тасвирламасындагы 2 пунктның беренче абзацына «бүләкләү» сүзеннән соң «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре,» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 16 апрель
№ ПУ-232

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның «__16__» апрелендәге
ПУ-232__ номерлы Указына
1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы
Президентының Рәхмәт сүзе
турында нигезләмәгә
$2^1$ нче кушымта

Татарстан Республикасы

______________________________
(район, шәһәр)

**Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеген Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе белән бүләкләүгә гариза кәгазе**

1. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге атамасы ________________________

________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге уставы нигезендә рус һәм татар телләрендә тутырыла)

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

2. Оешу датасы ________________________________________________

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең бүләкләре

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органы адресы, элемтә өчен телефон ____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

5. Бүләкләүгә тәкъдим ителә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең төп казанышлары ____________________________________________________________
(Татарстан Республикасы алдындагы казанышларын, җитештерүдә, фән өлкәсендә башка казанышларын

____________________________________________________________
күрсәтеп, ирекле формада тутырыла)

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Үтенечнамә биргән орган җитәкчесе

______________________________________________________________________________
(органның атамасы, вазыйфа күрсәтелә)

______________________________________________
имза Ф.И.Аи.

М.У.

20 ____ елның «____» ________________».

____________

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның « 16 » апрелендәге
ПУ- 232 номерлы Указына
2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы
Президентының Рәхмәт сүзе
турында нигезләмәгә
$2^2$ нче кушымта

**Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеген Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе белән бүләкләү турындагы үтенечнамәгә теркәп бирелә торган документлар* исемлеге**

1. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге (алга таба – муниципаль берәмлек) уставының аның атамасы турында рус һәм татар телләрендә мәгълүмат китерелгән битләре күчермәсе.
2. «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе бәяләмәсе.
3. Муниципаль берәмлек Татарстан Республикасы алдында казанышларга ирешкән эшчәнлек өлкәсендә идарә функцияләрен (функциональ җайга салуны) үтәүче республика башкарма хакимият органының муниципаль берәмлекнең Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенә өлеш кертүе турындагы белешмәләр кертелгән бәяләмәсе.
4. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының үтенечнамә кузгатылган ел алдыннан килгән соңгы биш елда һәм агымдагы елның узган айларында муниципаль берәмлекнең төп социаль-икътисадый күрсәткечләре динамикасы турында белешмәсе.
5. Татарстан Республикасы муниципаль районы вәкиллекле органының Татарстан Республикасының әлеге муниципаль районы составына керә торган муниципаль берәмлегенең Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары турында бәяләмәсе.

---

Искәрмә:

* Документлар бер ел эчендә гамәлдә дип санала.».